Мәмәшир авыл җирлеге Советы

К а р а р

15.02.2021 ел № 3

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авыл җирлеге Уставы нигезендә, Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затлар милкендәге җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны рациональ файдалану, саклау һәм яңадан җитештерү максатларында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек Башлыгы: И. Г.Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012

ИНН 1623001702

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авыл җирлеге Советы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә керми торган яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында Нигезләмә**

Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Урман кодексы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Мәмәшир авыл җирлеге Уставы нигезендә халыкның экологик иминлеген тәэмин итү максатларында эшләнде һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә керми торган яшел утыртмаланы кисү тәртибен билгели.

## 1. Төп төшенчәләр

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Яшел үсентеләр – табигый һәм ясалма чыгышлы агач, куак һәм үләнчел үсемлекләр (паркларны, скверларны, бакчаларны, газоннарны, чәчәклекләрне, шулай ук аерым үсеп утыручы агачларны һәм куакларны да кертеп).

Табигать территорияләре – бердәм географик (климат) шартларында формалашкан җирлек, туфрак, үсемлекләр рельефының билгеле бер типларын үз эченә алган, хуҗалык эшчәнлеге кагылмаган яисә аз кагылган территорияләр.

Яшелләндерелгән территорияләр – табигый чыгышлы үсемлекләр кишәрлекләре урнашкан территорияләр, ясалма рәвештә булдырылган яшелләндерү объектлары (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш), төрле функциональ билгеләнештәге җирләрнең алар чикләрендәге җир өслегенең 50 процентыннан да ким булмаган өлеше үсемлекләр белән капланган төзелеш аз булган кишәрлекләре

Урманга әверелгән территорияләр – табигый тишелеп чыккан урман үсемлекләре белән капланган төрле функциональ билгеләнештәге табигать территорияләре кишәрлекләре.

Агач – диаметры кимендә 5 см, биеклеге 1,3 м булган ачык беленеп торган кәүсәле үсемлек, яшь үсентеләрдән кала.

Куак – туфрак өслегендә үк тармакланган күпьеллык күптармаклы (агачтан аермалы буларак) үсемлек.

Үлән капламы – газон, табигый үләнчел үсемлекләр.

Куаклык, әрәмәлекләр (заросли) – нинди дә булса урында куе булып үсә торган үсемлекләр, куаклар.

Яшел массив – бердәм үрчү хасил итүче 50 данәдән дә ким булмаган зур (15 елдан күбрәк) агачлар үсә торган территория кишәрлеге.

Яшел утыртмаларны зарарлау – яшел утыртмаларга аларның үсешен туктатуга китерми торган зыян китерү, шул исәптән ботакларның, тамыр системасының механик зарарлануы, кабыкның, тере туфрак катламының бөтенлеге бозылу, яшел үсентеләрнең йә тамыр зонасында туфракның зарарлы матдәләр белән пычрануы, ут төртү яисә башка йогынты

Яшел утыртмаларны юкка чыгару (югалту) – яшел утыртмаларны кисү яки аларның үсешен туктатуга китергән башка төрле зарарланулар.

Компенсация рәвешендә яшелләндерү – юкка чыгарылган яисә зарарланган агачлар урынына 2 коэффициент белән яшел утыртмалар булдыру.

## 2. Яшел утыртмаларны саклауның төп принциплары

Авыл җирлеге территориясендә үсә торган яшел утыртмалар саклагыч, рекреацион, эстетик функцияләр башкара һәм сакланырга тиеш.

2.1. Авыл җирлеге территориясендә (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) урнашкан барлык яшел утыртмалар (агачлар, куаклар) якланырга тиеш.

2.2. Авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрне саклау һәм үстерү өчен шартлар тәэмин итү бурычлары түбәндәгеләргә йөкләнә:

оешмаларга үзләре күрсәткән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән кишәрлекләрдә – шушы оешмалар җитәкчеләренә;

2.2.2. милектәге яисә арендадагы кишәрлекләрдә – юридик затларга һәм гражданнарга – милекчеләр яисә арендаторларга.

2.3. Яшел утыртмалар урнашкан җир кишәрлекләренең милекчеләре, файдаланучылар һәм арендаторлары яшел утыртмаларның сакланышын тәэмин итәргә, яшел утыртмаларны тиешенчә карауны тәэмин итәргә тиеш.

2.4. Әлеге Нигезләмә барлык гражданнарга һәм, милек формаларына бәйсез рәвештә, авыл җирлеге территориясендә агач-куак үсентеләрен кисүгә бәйле рәвештә проектлауны, төзүне, ремонтлауны һәм башка эшләрне алып баручы оешмаларга кагыла.

2.5. Авыл җирлеге территориясендә хуҗалык, шәһәр төзелеше һәм башка эшчәнлек Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән яшел утыртмаларны саклау таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

2.6. Җир кишәрлеген сайлау акты, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшчәнлекне оештыруга проект алды һәм проект документациясендә яшел утыртмаларның торышы турында тулы һәм дөрес белешмәләр һәм проектлана торган объектның яшел утыртмаларга йогынтысын тулысынча бәяләү булырга тиеш.

2.7. Яшелләндерелгән территорияләрдән һәм яшел массивлардан яшел утыртмаларның тереклек эшчәнлеген тәэмин итми торган файдалану рөхсәт ителми.

## 3. Яшел утыртмаларны (агачларны, куакларны) кисү тәртибе

3.1. Авыл җирлеге территориясендә яшел утыртмаларны рөхсәтсез кисү тыела.

3.2. Авыл җирлеге территориясендә агачларны һәм куакларны кисү рөхсәт нигезендә башкарыла. Кисүгә рөхсәт Авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.

3.3. Яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәт алу өчен, мөрәҗәгать итүче Авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе исеменә билгеләнгән формада (1 нче кушымта) хат-заявка бирә, анда утыртмаларның саны, исеме, аларның торышы, чикләнгән кисү үткәрелү урыны һәм аны нигезләү күрсәтелгән булырга тиеш. Гаризага түбәндәге документлар теркәп бирелә:

3.3.1. 2. Шәхесне таныклый торган документлар;

3.3.2. Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш итә икән);

3.3.3. Якындагы корылмаларга яисә башка ориентирларга кадәр булган кишәрлекнең киселергә тиешле яшел үсентеләр төшерелгән схемасы;

3.3.4. Җир кишәрлеге Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлмәгән булса, җир кишәрлегенә хокук билгели торган һәм җир кишәрлеген раслаучы документларның таныкланган күчермәләре;

3.3.5. Биналар һәм корылмалар төзегәндә габаритларга эләгә торган яшел утыртмаларны кисү башкарылган очракта, расланган проект документациясе;

3.3.6. Әлеге мәсьәлә кагыла торган территорияләрнең хуҗалары белән яшел үсентеләрне кисү һәм күчереп утырту шартларын килештерү;

3.3.7. Агач утыртканда яисә күчереп утыртканда инженер челтәрләре вәкилләре белән җир эшләрен уздыруга ордер ачып килештерү.

3.4. Авыл җирлеге башкарма комитеты, хат-заявка кергәннән соң, Гариза бирүчегә әлеге эш төрен үткәрүгә рөхсәте булган махсуслаштырылган оешмага түбәндәгеләрне алу өчен мөрәҗәгать итәргә киңәш бирә:

3.4.1. яшел утыртмаларны исәпләү ведомосте;

3.4.2. киселергә тиешле агач-куак үсентеләренең санын, төрен, категориясен билгеләү максатында төзелә торган яшел утыртмаларны табигый техник тикшерү акты;

3.4.3. киселгән агач өчен бәянең (түләүнең) бәясен исәпләп чыгару. Киселгән агач өчен түләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары белән расланган ставкалар нигезендә аерым исәпләнә.

Югарыда күрсәтелгән эшләр Гариза бирүче хисабына башкарыла.
Рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты – 90 көн.

3.5. Авыл җирлеге башкарма комитеты Гариза бирүченең хат-заявкасы, яшел утыртмаларны табигый техник тикшерү акты, киселгән агач өчен бәяне (түләүне) исәпләп чыгару нигезендә авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт бирү турында Авыл җирлеге башкарма комитеты Җитәкчесенең күрсәтмә проектын әзерли.

3.6. Эшләр башкаруга рөхсәт алганда, аның мәнфәгатьләрендә яшел утыртмалар юкка чыгарыла торган Гариза бирүче, әлеге Нигезләмә нигезендә яшел утыртмаларны кискән өчен түләүләр кертергә һәм компенсация рәвешендә яшелләндерүнең тәртибен раслый торган документларны тапшырырга тиеш.

3.7. Агач һәм куакларны кискән өчен түләү Гариза бирүче тарафыннан Авыл җирлеге бюджетына күчерелә.

3.8. Яшел утыртмаларны кисү эшләре билгеләнгән нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә Гариза бирүче акчалары исәбенә башкарыла. Агачны бары тик аттестацияләнгән белгечләрнең кисүе генә рөхсәт ителә.

3.9. Яшел утыртмаларны егу, төпләү, киселгән яшел утыртмаларны һәм киселгән калдыкларны төяү һәм чыгару эш башланганнан соң өч көн эчендә Гариза бирүче хисабына башкарыла. Киселгән яшел утыртмаларны һәм киселгән калдыкларны эш урынында саклау тыела.

3.10. Территориянең кисү урынына якын урнашкан территориядә газон, яшел үсентеләр зарарланган очракта, территория хуҗасы һәм контроль органнары белән алар компетенциясе чикләрендә килештерелгән срокларда, әмма зыян килгән вакыттан ярты елдан да соңга калмыйча, эшләрне башкаручы аларны мәҗбүри торгыза.

3.11. Агачны кискән өчен түләмичә генә агач һәм куакларны кисү Авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге очракларда рөхсәт ителергә мөмкин:

3.11.1. яшел үсентеләрне тәрбияләү, санитар кисүләр һәм реконструкцияләү өчен кисүләр үткәрү;

3.11.2 авария һәм башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү, шул исәптән җир асты коммуникацияләрен һәм капиталь инженерлык корылмаларын ремонтлау вакытында;

3.11.3. Дәүләт санэпидемнадзор бәяләмәсе булса, торак һәм җәмәгать биналарында яктылыкны боза торган агач һәм куакларны кисү;

3.11.4. авария хәлендәге (авып төшү куркынычы тудыручы, коры-сары) агачларны һәм куакларны кисү.

3.12. Югарыда күрсәтелгән очракларда яшел үсентеләрне кисүне гамәлгә ашыручы Гариза бирүчегә Авыл җирлеге башкарма комитеты белән килештерелгән урыннарда компенсация рәвешендә яшелләндерү үткәрергә кирәк.

3.13. Авария хәлендәге, коры-сары һәм хәвеф-хәтәр тудыручы яшел утыртмалар 2 нче кушымта нигезендә акт нигезендә комиссияләр тикшерүе нигезендә киселә.

3.14. РФ Урман кодексының 20 статьясы аналогиясе буенча җир кишәрлегендә, аны гражданга яисә юридик затка милеккә тапшырганнан соң, хуҗалык эшчәнлеге

нәтиҗәсендә яки табигый рәвештә барлыкка килгән агач-куак үсемлекләре аның үзенчә файдалана һәм үзе теләгәнчә җитәкчелек итә торган үз милке булып тора.

3.15. Яшел утыртмаларны рөхсәтсез кисү яисә юкка чыгару дип түбәндәгеләр таныла:

3.15.1. агачларны һәм куакларны рөхсәтсез яисә рөхсәт белән кисү, ләкин рөхсәттә күрсәтелгән кишәрлектә һәм санда, күрсәтелгән төрләрен кисмәү.

3.15.2. яндыру яисә ут белән саксыз эш итү нәтиҗәсендә агачларны һәм куакларны юкка чыгару яки зарарлау;

3.15.3. кәүсәне бозралау яисә төпләү (подсечка);

3.15.4. үсеп килүче агачларның һәм куакларның үсеш туктатылганчы зарарлануы;

3.15.5. агачларның һәм куакларның агынты сулар, химик матдәләр, калдыклар һәм башка шундыйлар белән зарарлануы;

3.15.6. коры-сары агачларны рөхсәтсез кисү;

3.15.7. үсә торган агачларның һәм куакларның башкача зарарланулары.

3.16. Дәүләт урман фондында булган агачларны һәм куакларны кисү махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан бирелгән рөхсәтләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.17. Әлеге Нигезләмәне бозып, агачларны һәм куакларны юк итү рөхсәтсез кисү булып тора һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә административ һәм җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш. Әлеге Нигезләмә кагыйдәләрен үтәү авыл җирлеге территориясендә барлык гражданнар, оешмалар һәм учреждениеләр өчен мәҗбүри.

## 4. Компенсация рәвешендә яшелләндерү

4.1. Компенсация рәвешендә яшелләндерү рөхсәт ителгән кисүләр, яшел үсентеләрне законсыз зарарлау яки юкка чыгару очракларында гамәлгә ашырыла. Компенсация рәвешендә яшелләндерү агачлар, куаклар һәм газлар утырту өчен яраклы якындагы сезонда, әмма яшел үсентеләрне зарарлау яки юкка чыгару факты билгеләнгән вакыттан алып бер елдан да соңга калмыйча башкарыла.

4.2. Компенсация рәвешендә яшелләндерү мәнфәгатьләрендә яисә хокукка каршы гамәлләр нәтиҗәсендә яшел үсентеләрне зарарлаган яки юкка чыгарган гражданнарның яисә юридик затларның акчалары хисабына башкарыла.

4.3. Әлеге Нигезләмә нигезендә яшел утыртмаларга китерелгән зыян табигый формада – компенсация рәвешендә яшелләндерү формасында кире кайтарылырга тиеш: юкка чыгарылган агачлар урынына 2 коэффициент белән яшел утыртмалар булдыру.

## 5. Яшел утыртмаларны саклау шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда

5.1. Авыл җирлегендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру яшел утыртмаларны саклау таләпләрен үтәп алып барыла.

5.2. Яшел территорияләр, шул исәптән яшел массивлар, шулай ук яшелләндерелгән территорияләрне үстерү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре, аларның максатчан билгеләнешенә бәйле булмаган килеш кулланылырга һәм анда төзелеш алып барылырга тиеш түгел.

5.3. Яшел утыртмалар утыртылган җир кишәрлекләрендә төзелеш алып барганда, проект документациясендә киселергә тиешле яшел утыртмаларга бәя булырга тиеш. Мондый очракларда зыянны каплау киселгән агач өчен түләүне алдан кертү һәм әлеге Нигезләмәнең 2 һәм 3 бүлекләрендә билгеләнгән тәртиптә компенсация рәвешендә яшелләндерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 6. Яшел утыртмаларны саклау
## Эшмәкәрлек эшчәнлеген башкарганда

6.1. Яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда Авыл җирлеге башкарма комитеты рөхсәтеннән башка сәүдә һәм башка эшмәкәрлек эшчәнлеге, эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен палаткалар һәм башка корылмалар урнаштыру тыела.

6.2. Эшмәкәрлек эшчәнлеген яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда гамәлгә ашырганда шартлау куркынычы булган, ут куркынычы булган һәм агулы матдәләр куллану, территорияне пычрату һәм чүпләү, яшел утыртмаларның зарарлануына яки юкка чыгуына китерергә сәләтле башка эшләр тыела.

## 7. Административ җаваплылык.

7.1. Әлеге Нигезләмәне бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы булалар.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында Нигезләмәгә 1 нче кушымта

Мәмәшир авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Җитәкчесенә
___________________________
__________________________
___________________________
__________________________
(оешманың исемен
яки Ф.И.О., адресын күрсәтергә)

МӘМӘШИР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТЕРРИТОРИТОРИЯСЕНДӘ
АГАЧ-КУАКЛАР ҮСЕНТЕЛӘРЕН ЧИКЛЕ КҮЛӘМДӘ КИСҮГӘ
**ГАРИЗА**

Агачларны, куакларны, агач-куак үсемлекләрен (кирәклесенең астына сызарга) кисүне рөхсәт итүегезне сорыйм, алар ________________________ ______________________________ ______________________________________________________________________ җир кишәрлегендә
(оешманың исемен яисә Ф.И.О. һәм җир кишәрлегенә хокукның төрен күрсәтергә)
һәм ____________________________________________________________ җирләрендә урнашкан
(торак пунктны күрсәтергә)
Җир кишәрлеге түбәндәгеләр булу белән характерлана:
агачлар __________________________________ данә
куаклар __________________________________ данә
Җир кишәрлеген үзләштерү һәм төзекләндерү процессында агачны кискән өчен түләүне гамәлгә ашырырга һәм дендроплан нигезендә агач-куак үсентеләрен компенсация рәвешендә утыртуны башкарырга сүз бирәм.

_______________ ________________
Ф.И.О. (Имза)
Дата _____________

Кушымталар:
1. Исәп-рөхсәт документлары.
2. Кисү күздә тотыла торган яшел утыртмаларның төре һәм саны күрсәтелгән җир кишәрлеге планы.

ТР Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә РФ дәүләт урман фонды җирләренә керми торган яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында Нигезләмәгә 2 нче кушымта

ЯШЕЛ УТЫРТМАЛАРНЫ КИСӘРГӘ ЯРАКЛЫ ДИП ТАНУ ТУРЫНДА **АКТ**

Кукмара муниципаль районының МӘМӘШИР авыл җирлеге башкарма комитеты
«_____»_____________________________________________________________ ел

Әлеге составтагы комиссия
1._____________________________________________________________
(Ф. И. О., вазыйфасы)
2._____________________________________________________________
(Ф. И. О., вазыйфасы)
3._____________________________________________________________
(Ф. И. О., вазыйфасы)
яшел утыртмаларны тикшерү үткәрде.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча билгеләнде:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________

Нәтиҗәләр:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
__________________________________________________________________

Комиссия әгъзалары:

1. ________________________ ________________________
(имза) (ФИО)
2. ________________________ ________________________
(имза) (ФИО)
3. ________________________ ________________________
(имза) (ФИО)